ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

14 09 2021 г. № 799

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 июнендәге 610 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 36 һәм 67 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 2 июлендәге 310-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 18 июнендәге 610 номерлы карары белән расланган «Гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына алу турында гаризалар кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2.1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2.1.3. Бала аның бертуган һәм төрле этидән (әнидән) туган абыйсы һәм (яки) апасы белем алган муниципаль мәгариф оешмасына мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул итү хокукына ия.».

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ» МКУ * РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МКУ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА» *
ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044874